| | | |
|---|---|---|
| **ТАТАРСТАН**<br><br>**РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**ЧИРМЕШӘН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**БӘРКӘТӘ АВЫЛ**<br>**ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** | | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ЧЕРЕМШАНСКИЙ**<br>**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**<br>**СОВЕТ**<br>**БЕРКЕТ-КЛЮЧЕВСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** |
| **423106, БӘРКӘТӘ АВЫЛЫ,**<br>**ЛЕНИН УРАМЫ, ЙОРТ 76 “а”** | **тел.+7(84396)**<br>**2-64 -66**<br>**тел./факс**<br>**+7(84396) 2-64-66** | **423106, СЕЛО БЕРКЕТ- КЛЮЧ,**<br>**УЛИЦА ЛЕНИНА, ДОМ 76 «а»** |


№ 8 11.12.2025

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Бәркәтә авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Бәркәтә авыл җирлеге Советына Бәркәтә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2026 елга җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә бюджет ассигнованиеләре бүлеп бирү турындагы мөрәҗәгатен карау хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 77 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 октябрендәге 288-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Башкарма комитетның 2025 елның 13 ноябрендәге №127 карарын карап, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге Советы

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2026 елга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге бюджетына бюджет ассигнованиеләренең җитәрлек булмавын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Бәркәтә авыл җирлеге башкарма комитеты мөрәҗәгатендә күрсәтелгән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә аерым вәкаләтләрне финанслаудан кушымта нигезендә баш тартырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVOTATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.
2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районының
Бәркәтә авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.М.Сибгатуллин

Советның 2025 елның 11 декабрендәге
8 номерлы карарына
1 нче кушымта

**2026 елда бюджет ассигнованиеләрен бүлеп бирү өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләр исемлеге**

| №<br>№<br>п\п | Бюджет ассигнованиеләре белән ныгыту өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрнең аталышы | Барлыгы, мең сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Гидротехник корылманы декларация алды тикшерүе | **0,0** |
| 2 | “Эчә торган суның сыйфатын СанПинның билгеләнгән таләпләренә туры китерү” | **250,0** |
| 3 | “Су белән тәэмин итүгә лицензия алу өчен документлар әзерләү” | **1000,0** |
| 4 | Җир асты чыганакларын санитар саклау зоналары проектын эшләү | **500,0** |
| 5 | Шәһәр төзелеше планын әзерләү | **1200,0** |
| 6 | Янгын гидрантларын ремонтлау һәм алыштыру | **50,0** |
| 7 | Дератизация чараларын үткәрүне тәэмин итү | **50,0** |
| 8 | Эшчәнлек төренә санитар-эпидемиологик нәтиҗә алу | **30,0** |
| 9 | Җирле әһәмияттәге юлларны карап тоту өчен махсус реагентлар сатып алу | **200,0** |
| 10 | Рөхсәтсез чүплекләрне рекультивацияләү | **0,0** |
| 11 | Янгын сүндергечләр сатып алу, тутыру | **10,0** |
| 12 | Янгынга каршы түбә һәм сәхнә тартмасы пропиткасы | **350,0** |
| 13 | Янгын сигнализациясен ремонтлау | **0,0** |
| 14 | Металлодетекторлар сатып алу | **20,0** |
| 15 | Тавыш белән ашыгыч хәбәр итүнең автоном системасын урнаштыру | **25,0** |
| 16 | Видеокүзәтү системасын урнаштыру, ремонтлау | **250,0** |
| 17 | Гидротехник корылмаларны карап тоту | **0,0** |
| 18 | Юл билгеләрен урнаштыру | **40,0** |
| 19 | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар булдыру | **0,0** |
| 20 | Гидрант күрсәткечләрен урнаштыру | **50,0** |
| 21 | Санкцияләнмәгән карьерларны рекультивацияләү | **0,0** |
| 22 | Эшләрнең башка төрләре | **0,0** |
|  | **БАРЛЫГЫ, мең сум** | **4025,00** |